**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛАНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Школьная ул., д. 1, с. Алан, 422085
тел.: (84360) 54-1-13,
E-mail: Alan.Tul@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
АЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Мәктәп ур., 1 нче йорт, Алан авылы, 422085
тел.: (84360) 54-1-13,
E-mail: Alan.Tul@tatar.ru

ОКПО 93053621 ОГРН 1061675010176 ИНН/КПП 1619004387/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**№ 15** **«13» август 2020 ел**

Теләче муниципаль районының Алан авыл җирлеге территориясендә дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Президентын һәм Алан авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары депутатларын сайлаулар буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар билгеләү турында

«2020 елның 13 сентябрендә җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары депутатларын сайлауларда сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү һәм җиһазлау турында җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү хакында» Татарстан Республикасы Теләче районының 2020 елның 28 июлендәге 14/22 номерлы территориаль сайлау комиссиясе карарын карап, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге Башкарма комитеты,

## КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районының Алан авыл җирлеге территориясендә дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Президентын һәм Алан авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары депутатларын сайлаулар буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен түбәндәге махсус урыннарны билгеләргә:

-Алан авылы, Октябрь урамы, 210А йорт, ИП "Хәкимова" кибете бинасында»;

-Балыклы авылы, Ленин урамы, 8 йорт, ИП "Хәкимова" кибете бинасында»;

- Күкчә авылы, Шоссе урамы, 21А йорт, ИП "Хәкимова" кибете бинасында»;

- Ключище авылы, Үзәк урамы, 16-нчы номерлы йорт янында мәгълүмат стенды.

2. Алан авыл җирлеге башкарма комитетының «Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге территориясендә алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советына депутатлар сайлау буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар билгеләү турында» 2019 елның 25 нче июлендәге 26 нчы номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Теләче районы территориаль сайлау комиссиясенә җибәрергә.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарны Алан авыл җирлегенең мәгълүмат стендында түбәндәге адрес буенча : 1 нче йорт, Мәктәп урамы, Алан авыл җирлеге башкарма комитетының административ бинасында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Теләче муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

Алан авыл җирлеге башкарма комитет
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Б.Н.Хәсәнов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ИНН 1619004307